# Яшьлек

Минзәлә шәһәре гимназиясе

Киләчәкнең башы - бүгенгедә

1998

Октябрь, 2017 ел




## Белем чишмәбез




## Атна шәхесе - Айзилә!



## Мәктәптәге әнием син!

# Әх, туган көн!




Әле кайчан гына Татарстан балалары безнең илдә, беренчеләрдән булып, «Россия укучылары хәрәкәте» дип аталган яңа оешмага керде. Баксаң, моңа ике ел узып та киткән.

Нәкъ менә ике ел элек, 29 октябрьдә әлеге хәрәкәт Россия Президенты Указы белән илдә үз эшен башлап җибәрде. Рәсми, шул ук вакытта иҗтимагый оешма булган әлеге хәрәкәткә Татарстандагы 50 мәктәптән иң яхшы 50 укучы бала кабул ителде. Алар арасында гимназиябезнең 9 нчы сыйныф укучысы Низамова Сөмбел дә бар иде. Ә инде бүгенге көндә безнең мәктәптә генә дә иң актив, ин үрнәк, ин алдынгы һәм сәләтле 30 укучы әлеге хәрәкәттә “кайный”. Хәер, без районда бу эшне башлап җибәргән бердәнбер мәктәп булуга карамастан, быел инде калган мәктәпләр дә «Россия укучылары хәрәкәте»е агымына кушылып киттеләр.
Шунысы кызык, былтыр Татарстанда «Россия мәктәп укучылары хәрәкәте»нә кушылган мәктәпләрнең саны 53 кенә булган. Хәзер бу хәрәкәттә – республикабызның 600 мәктәбе. Бүген Россиядә 8000 мәктәп, 9 миллион укучы «Россия мәктәп укучылары хәрәкәте»нә кергән.

«Россия укучылары хәрәкәте» күпләр өчен зур бер гаиләгә әверелде . Шушы ике ел дәвамында ул һәрвакыт бары тик яңа мөмкинлекләр генә ачты. Әлеге хәрәкәттә – илне яхшы якка үзгәртергә теләүчеләр. Алар яңа проектлар ясый, профессияләрне популярлаштыра, волонтерлык эше белән дә шөгыльләнә. Шул ук вакытта бу хәрәкәт Россия киңлекләренә ишек ача.

Шушы хәрәкәтнең туган көне уңаеннан Минзәләнең балалар иҗат йортында бик матур бәйрәм узды. Әлеге бәйрәм традицион рәвештә гимназия укучылары флэшмобы белән башланып китте, шулай ук бик кызыклы һәм актуаль темаларга “Дебатлар” уены үткәрелде. Бәйрәм ахырында, әлеге хәрәкәтнең эшен районыбызда нәкъ менә гимназия укучылары башлап җибәргәнгә күрә, тантаналы рәвештә безгә “Россия укучылары хәрәкәте”нең әләме тапшырылды, һәм һавага шарлар җибәрелде!



Кыскасы, Минзәләдә туган көн гөрләп узды!

# Атна шәхесе-Айзилә



Бу айның шәхесе– Айзилә! Ул бик мәрхәмәтле, позитив һәм креатив кыз Барлык мәктәп чараларында, район конкурсларында ул актив катнаша. Алдагы тормыш юлында аңа уңышлар теләп калабыз.

**Туган көне : 22.03.07**
**Ф.И.О.: Исхакова Айзилә Илнар кызы**
**Яраткан фильмы: «Взломать блогеров, последний богатырь»**



**- Сәлам, Айзилә!**

- Сәлам.

- **Әгәр дә, "вакыт машинасы"на утырып, үткәнгә кайтып булса, син нәрсә үзгәртер идең?**



**-** Бер әйберне дә үзгәртмәс идем, миңа барысы да ошый (елмая).

- **Тормышыңда синең өчен ни мөһим?**

**-** Гаиләм һәм сәламәтлек.

- **Синең тормышыңда берәр нинди уйланылмаган адым ясаганың булдымы?**

- Алла сакласын, андый хәлләрнең булганы юк һәм була да күрмәсен (көлә).

**- Син үзеңне уңышлы кеше дип саныйсыңмы?**

- Әйе, мин бик уңышлы кыз.

**- "Эх, туган көн, туган көн..."дигән җырны дәвам ит.**

**-** Туганнар җыелган көн,
җан дусларым белән бергә
күңел ача торган көн.



**- Нинди 3 әйбердән куркасың?**

-Туганнарны югалтудан, икеле алудан һәм еланнан.

- **Нинди һөнәр сайлыйсың килә?**

**-** Актриса булырга хыялланам.

**- Елга планнарың нинди?**

- ВПРларны 4 һәм 5 билгеләренә генә эшләргә.





Җәмилова Айзилә

# Өлкәннәр көне



Өлкән сүзен ишеткәч, сез кемне күз алдына китерәсез? Сезнең өчен өлкән кеше ул сездән олырак булган кешеме? Бәлки әни-әтиегез, әбибабагыздыр, бәлки сез зирәк кешене өлкән дип уйлыйсыздыр.

Чыннан да, кем соң алар өлкәннәр? Өлкән кеше ул инде үзе яшәгән гомерендә күпмедер булса да тәҗрибә җыйган һәм шул тәҗрибәне үзенең хезмәтендә бик оста куллана белә торган, аны кечкенә буын дәвамчысыларына бирергә әзер. Без өлкән кешедән еш кына киңәш белән ярдәм сорарга ияләшкәнбез, чөнки без аларның хаклыгын беләбез. Кызганычка каршы, без кайвакытларда өлкәннәр белән сөйләшкәнне онытып җибәрәбез, кайвакыт тавыш күтәреп җибәргән чаклар да була. Шул вакытларда безгә тавыш күтәрүдән тыелырга кирәк, без өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәнергә, сабыр булырга тиешбез.



Искә төшерегез әле, күпме тапкыр әниәтиегез яки әби-бабаегыз сезгә ярдәм итте, киңәш бирде, дөрес юлга бастырды. Ә хәтерлисезме, кайчан соңгы тапкыр аларга "яратам", "рәхмәт" дигәнегезне? Юкмы? Алай булса, әйдәгез, өйгә кайткач, аларны кочаклап алыгыз, җылы сүзләр әйтегез. Без өлкәннәрнең кадерен белергә тиеш. Соң булырга мөмкин. Без бит алар белән аерылышу көнен белмибез, бәлки, ул бик тиздән булыр.

Гимназия балалары да Өлкәннәр көненә концерт оештырдылар, сыйныфлар бүләкләр әзерләде. Кунакка килгән өлкәннәрне шулай җылы итеп каршы алдылар. Иң мөһиме - өлкәннәрне һәрвакыт хөрмәт итегез.







*Шәрифуллина Рүзилә*

# Мәктәптәге әнием син...



Иң кадерле мөгаллимем минем,
Гыйлем чишмәләрең кипмәсен!
Һәрчак ташып торсын көч-куәтең,
Яшәү дәртең мәңге сүнмәсен!

Укытучы! Һәркайсыбызның иң матур хатирәләре, шатлык-борчулары, беренче дулкынланулары нәкъ менә мәктәп һәм укытучы белән бәйледер, дип уйлыйм мин. Беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, бала белән янәшәдә аның укытучысы атлый, әйдәп бара. Ул дөньядагы барлык матур сыйфатларны үзенә туплаган. Киң күңеллелек, тырышлык, балаларга чиксез мәхәббәт, намуслылык...

Аның безне беренче тапкыр каршы алуы, иплəп кенә кулыбыздан тотып, якты сыйныфка алып керүе бүгенгедәй хәтеребездә. Нечкә тавыш белән әйткән сүзләре әле дә колагыбызда яңгырап тора... Гадел һәм түземле, тыныч һәм ягымлы. Безнең уңышларга сөенә, кайгыларыбызны уртаклаша. Дәресләрне дә аңлаешлы һәм күңелле итеп үткәрә бит алар. Алар белән бергә без мәктәп тормышындагы һәрбер эштә бик актив катнашабыз. Бездән чын шәхес тәрбияләүгә бөтен көчләрен бирәләр. Алар укытучылар гына түгел, ә артист та, язучы да!

Укытучы булу җиңел түгел. Ул зур сабырлык, балаларга карата олы мәхәббәт һәм сайлаган һөнәргә карата чиксез бирелгәнлек таләп итә. Киләчәктә нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә, уңышларыбзның башында укытучы торганын онытмыйк. Без укытучыларыбызны бик яратабыз һәм хөрмәт итәбез. Аларга авыр һәм мактаулы эшләрендә зур уңышлар, сәламәтлек теләп калабыз!

Укытучылар көне уңаеннан безнең гимназия балалары да үзләренең яраткан укытучыларын котлап уздылар. Алар исә укытучыларны моңлы җырлары, ягымлы сүзләре белән каршы алдылар һәм көн дәвамында яхшы кәеф бүләк иттеләр. Мондый матур көннәр күбрәк булсын иде дөньяда!









*Җәмилова Айзилә*

# Белем чишмәсе



И китап, кайсы гасырның
Серләре эчләрендә?
Өлешең зурдан тарихның
Бар изге эшләрендә.

Китсә дә татар баласы,
Сөрелеп илдән-йорттан,
Иң элек газиз китабын
Коткарып калган уттан.



Октябрь аенда күптән көтелгән вакыйга булды: китап чыгарылды. Сез, бәлки: «Китап чыга тора инде ул, шуннан нәрсә?» - дип тә уйларсыз. Тик бу китап һәр гимназия укучысына, әти-әниләргә, укытучыларга кадерле: монда безнең “Илһам”, “Глаголица” кебек бәйгеләрдә катнашкан, урын алган иҗат җимешләре дөнья күрде! Үз исемеңне китап битләрендә күрү шундый бәхет икән ул, күпме сөенеч китерә! Әлеге китап ачык яшел төстә, тышына матур итеп “Илһам чишмәм—белем бишегем” дип язылган, тиражы - 100 данә.

Китап табадан төшкән көнне үк Сарман, Актаныш районнарының татар теле һәм әдәбияты укытучыларына да бүләк итеп җибәрелде. Укытучылар мондый кадерле бүләккә сөенеп, мең рәхмәтләр укыдылар, бу шатлыклы вакыйганы бүлештеләр. Китап татар теле укытучылары, шигырь язган укучылар һәм безнең даими иганәчебез Гөлназ апа Хәбированың матди ярдәме белән чыгарылды. Макулатура җыеп тапшырган акчалар да шушы максатка ярап куйды.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: киләчәктә дә бу эш туктамасын иде, ә сез, укучылар, хикәяләр-шигырьләр иҗат итүдән туктамагыз. Ә без ышанып калабыз: тиздән безнең мәктәп укучыларның хикәя-шигырьләреннән торган икенче җыентык та дөнья күрер!








*Сәхәбетдинова Регина*

# Туган көн- гомер бәйрәме...

Туган көн- гомер бәйрәме...



**Укытучылар:**
Энже Фәвисовна (09.10)
Елена Николаевна (15.10)
Әлфия Наиловна (19.10)
Эльвира Илдаровна (20.10)
Фәридә Фәйзрахмановна (21.10)

**1 нче сыйныф:**
Хәлимов Нурсолтан (21.10)

**2 нче сыйныф:**
Исмәгыйлов Ильяс (7.10)
Хныкин Кирилл (3.10)

**4 нче сыйныф:**
Газизова Язилә (1.10)
Гыйбадуллина Зәрия (24.10)

**5 нче сыйныф:**
Фәрдиев Илнар (5.100
Исламова Лилия (29.10)

**8 нче сыйныф:**
Әхмәтова Алсу (2.10)
Мәрданова Диләрә (5.10)
Урсметова Эльвина  (10.10)
Фәррәхов Илнур (20.10)

**9 нчы сыйныф:**
Авзалтдинова Гүзәл (23.10)

**10 нчы сыйныф:**
Сираева Элиза (2.10)
Захарова Эльвина (23.10)
Фарманян Ани (26.10)







**Баш мөхәррир** —Низамова  Сөмбел
**Әдәби консультант-**  Җәмилова Айзилә
**Бүлек мөхәррирләре** - Хәбирова Наилә
**Проект җитәкчеләре** —    татар теле һәм әдәбияты укытучылары
Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745